НЕФТЬ һӘМ ХИМИЯ

Рөстәм Миңнеханов инновацион проектлар белән танышты

> 2

ТУЛА САМАВЫРЫ

Нәгыймуллиннар белән Латыйповлар нәселен берләштерүче ядкарь ул

> 3

ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕ

Хәтта агрономия законнары эшләрлек тә мөмкинлек юк бит...

> 4

ЖЫР БӘЙРӘМЕ

«Татар радиосы» 20 еллыгын билгеләп үтте

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 74 (28847) | Шимбә | 28 май | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

СОҢГЫ ВАГОНГА БИЛЕТ БАРМЫ?

Җәйге ял – 2022

Лагерьга юлламаны яз башында ук сатып алган әти-әниләрнең күңеле тыныч. Бу хакта хәзер генә исенә төшкәннәр исә: «Балалар җәйге ялсыз калмасмы?» – дип борчыла. Иртә алсаң, эш пешә шул. Татарстанда юллама бәяләре 900 сумнан башлап, 62 мең сумга кадәр тирбәлә. Соңгы юлламаларны кайдан табарга?

Лагерьның бер тәмен белгәннәр анда ел саен барырга атлыгып тора. Әнә Казанда яшәүче җиде бала тәрбияләүче Виктория Усинаның да ул-кызлары җәйне әйдаман апалары, яңа танышлары белән уздырырга ярата. Тик ул әлегә юллама сатып алырга өлгермәгән. Югыйсә апрельдән үк эзли башлаган. Хәзерге вакытта хосусый лагерьларда бәяләр 40–50 мең сумга җитә, аларда кешбэкны (юллама бәясенең яртысын) да кире кайтырып булмый.

– Зурлары үсеп бетте инде. Кечкенә кызыбызга – 8 яшь. Аны ике ел лагерьга илттем. Яз көне «Заречье» лагеренда кечкенәләр өчен биш көнлек сменада булды. Моңа кадәр Чистай, Чирмешән кебек ерак районнарга да җибәрдек. Тик хәлләрен белешергә бара алмагач, елый башлыйлар иде. Якында гына түгел бит. Узган ел Казандагы «Солнечный» лагере бик уңайлы булды. «Әни, конфит бетте», – дигән саен илтә идек. Шуңа күрә төпчегебез безне әллә ни юксынмады. Быел диңгезгә җибәрмәкче идек. Тик ул бөҗәкләрдән, яшеннән курка. Шуңа күрә лагерьны үзебездә эзлибез, монда аны тынычландырып була. Аптырагач, «Җәй» үзәгенә шалтыраттым. Анда, юлламасыз калмассыз, дип тынычландырдылар, – ди Виктория.

Быел лагерьларда ял итүче балаларны нинди яңалыклар көтә? Татарстан Яшьләр эшләре министрлыгының балаларның ялын оештыру буенча «Җәй» республика үзәге директоры Илдар Дәүләтшин әйтүенчә, лагерьларда «әти-әниләр көннәре» булмаячак. Әлеге чикләүләр быел да саклана. Кешбэк программасы дәвам итә. Быел чатырлы лагерьларда ял итүчеләр дә мондый мөмкинлектән файдалана ала. Россия Мәдәният министрлыгы беренче тапкыр «Страна героев» дигән проект булдырган. Аның нигезендә Татарстанга аз керемле балалар өчен бушлай 1 мең юллама бирелгән. Тиздән Яшел Үзәндә «Мирас» дип аталган яңа этномәдәни лагерь ачылачак. Ел дәвамында эшләүче үзәктә балалар республикада яшәүче төрле халыкларның үзенчәлекләрен өйрәнәчәк. Гомумән, ел саен яңа программалар булдырыла. Әти-әниләрне бигрәк тә физкультура-сәламәтләндерү, лидерлык, волонтерлык, чит телләр өйрәнү, төрле фәнни юнәлешләр кызыксындыра икән. Дәүләт ярдәменә мохтаҗ гаиләләрдә тәрбияләнүчеләргә бушлай 11,5 мең юллама каралган. Узган елга кадәр квота бирү Яшьләр эшләре министрлыгына йөкләнсә, быелдан районнар үзләре хәл итә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бер көн элек Татарстан Иҗтимагый палатасы да «кайнар элемтә» оештырган иде. Анда да күбрәк юлламалар сатып алу тәртибе белән кызыксындылар. Шулай ук: «Баланы 6 яшьтән җибәреп буламы?», «Берничә лагерьга барырга ярыймы?» кебек сораулар бирүчеләр дә булды. Казанда яшәүче, алты яшьлек баласын лагерьга илтергә теләгән Мариягә: «Республикада лагерьларга 7 яшьтән башлап 18 яшькә кадәрге балаларны кабул итәбез. 6 яшьлек сабыйлар өчен бер атналык ияләшү сменалары эшли. Мондый мөмкинлек «Костер», «Мирас», «Байтик»та бар», – дип җавап бирделәр. Балалар берничә лагерьда ял итә ала, чикләүләр юк.

– Кешбэк программасы кертелгәннән бирле әти-әниләр юлламаларны берничә көн эчендә алып бетерә. Хәзерге вакытта әти-әниләр узып баручы поездның соңгы вагоннарына утырып калырга тырыша. Безнең карамакта биш лагерь исәпләнә. Июнь аена юлламалар сатылып бетте инде. Июль – августта барырга теләүчеләр өчен «Мечта», «Чайка», «Дзержинец» лагерьларында гына буш урыннар бар. 182 мең юлламаның 84 меңе – шәһәр яны лагерьларына бирелсә, 11 мең бала – чатырлы, калганнары мәктәп яны лагерьларында ял итәчәк. Шәһәр яны лагерьларында хәзер 18 меңләп юллама булса да, акчаны соңрак түләү шарты белән әти-әниләр бронь алып куйды, – диде «кайнар элемтә»дә катнашкан Илдар Дәүләтшин.

Аның әйтүенчә, Татарстанда башка төбәкләргә караганда, шәһәр яны лагерьлары күбрәк, соңгы вакытта яңалары төзелү, төзекләндерелүгә карамастан, балалар саны арта. Бездә лагерь яшендәге 600 мең бала һәм аларга 218 мең урын бар. Тиздән мәктәп яны, хезмәт һәм ял, чатырлы лагерьлар эшли башлар.

Күптән түгел социаль челтәрләрдә, юллама бәяләре 50–60 мең сумга җитте, дигән хәбәрләр күренде. Бу хакта Казан балалар һәм яшьләр комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Светлана Миронова да, юллама бәяләренең 3,3–55 мең сум булуын әйткән иде. «Быел әти-әниләр түләве узган елдагы кебек саклана. Юллама бәясенең бераз гына артуы тукланууга бәя күтәрелү белән бәйле», – ди Светлана Миронова.

Нигә кыйммәт, арзанрагын кайда табарга була?

– Бәяләрне без дә, лагерьлар буенча федераль үзәк тә атна саен тикшереп тора. Әти-әниләр түләве уртача 12–22 мең сумга төшә. Бүген хосусый лагерьларда 62 мең сумлык сменалар да бар. Монда туклану, өстәмә хезмәтләр һәм башкасы керә. Шул ук вакытта районнарда 18 көн ял итү нибары 900 сумга төшкән очраклар да юк түгел, – диде Илдар Дәүләтшин. – Шартлар турында әти-әниләргә лагерь директоры белән сөйләшү яхшырак. Монда баланың теләге мөһим. Барлык лагерьлар турында мәгълүмат бирүче бердәм система юк. Йә «Җәй» республика үзәге, йә яшәү урыны буенча яшьләр бүлегенә мөрәҗәгать итеп, киңәшләшергә мөмкин.

Сәрия МИФТАХОВА

КИҢ МӘЙДАН СИҢА, КАРАВОН!

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм МИҢНЕХАНОВның Каравон рус халык бәйрәмен уздыру уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле татарстанлылар!

Сезне рус халкының үзенчәлекле, ямьле бәйрәме – Каравон уңаеннан чын күңелдән тәбрик итәм!

Үткәндәге ерак чорларда ук барлыкка килгән, православие традицияләре белән үрелеп, ярашып халыкның рухи тормышында зур урын алган бу мәдәни вакыйга гүзәл табигате һәм талантлары белән дан тоткан Лаеш җирендә хәзер дә гөрләп уза. Каравон – халык мәдәнияте күгендәге нурлы йолдыз, җан аваздашлыгы, якты уйлар, иҗади күтәренкелек тантанасы.

Бу бәйрәм борынгыдан Никольское авылында уздырыла, анда бүгенгебез белән үткәнебез, төрле буын вәкилләре очраша, милли үзаң нигезләре салына. Кадерләп саклап, яшьләребезгә мирас итеп тапшырыла килгән йола җырларында, уеннарда, төрле гореф-гадәтләрдә, халык иҗатында, тылсымлы көзгедәге сыман, рус халкының матурлыкка һәм татулыкка, азатлыкка һәм хакыйкатькә, тынычлыкка һәм әйләнә-тирәдәгеләр белән килешеп яшәргә, Илаһ һәм табигать белән бербөтенлек хисен тоярга омтылу кебек иң күркәм сыйфатлары ачык чагылыш таба.

Николай храмы кыңгырауларының моңлы чыңы, озын көйләр яңгырый, кулга-кул тотынышкан кешеләр, түгәрәк ясап, салмак кына атлый, аларның сафына төрле милләт һәм төрле дин вәкилләре өстәлеп, әйлән-бәйләннең колачы киңәя бара. Быел Каравон фестиваль форматында утызынчы тапкыр уздырыла, бу исә – борынгы тантананың башлангычы, аның традицияләре турында фикер алышу, шатлыклы мизгелләр кичерү өчен менә дигән форсат.

Илебез халыкларының һәм этник берлекләренең үзенчәлекләрен, милли-мәдәни төрлелеген саклауны да максат итеп куйган Россия халыкларының мәдәни мирасы елында Каравонны уздыру аеруча истәлекле вакыйга булачак.

Бәйрәмнең кунакларына, анда катнашучыларга, күтәренке кәеф, тынычлык, бәхет, игелек һәм иминлек телим.

Киң мәйдан сиңа, Каравон!

Рекордлы уңыш көтелә

Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы белдергәнчә, быел илдә рекордлы күләмдә ашлык җыеп алу көтелә. Ул, узган елдагыдан күпкә артып, максималь күрсәткечкә җитәргә мөмкин.

ТАСС хәбәренә караганда, 50 миллион тонна бөртекне чит илгә чыгару күздә тотыла. Экспорт квотасы үзгәрешсез калачак. Авыл хуҗалыгы министры Дмитрий Патрушев әйтүенчә, кирәк булган очракта, ашламаларны читкә чыгаруны чикләү озайтылырга мөмкин. Белгечләр фикеренчә, быел Россиядә ашлык уңышы 130 миллион тоннага җитәргә мөмкин. Узган елда бу күрсәткеч 120 миллион тоннадан артыграк булган.

РКБда – яңалык

Республика клиник хастаханәсе табиблары тез һәм оча сөяге буыннарын илебездә җитештерелгән эндопротезга алыштыра башлаганнар. Моңа кадәр Идел буе федераль округында Америка һәм Швейцариядә эшләнгән ясалма буыннардан гына файдаланылган. Хәзерге вакытта тез буынын алыштыру буенча операциягә – 2,9 мең кеше, оча сөяге буынын алыштыруга 913 кеше чиратта тора. «Моңа кадәр, төрле сәбәпләр аркасында, илебездә ясалма буыннар җитештерүче предприятие күләгәдә калып килде. Соңгы елларда моның белән «ЦИТО» шөгыльләнә. Әлеге предприятиенең продукциясе Мәскәүдә сирәк кенә кулланылды, әмма үзәктән читкә чыгарылмады», – ди РКБ баш табибы урынбасары профессор Михаил Бурмистров.

Сүз уңаеннан, РКБда һәр ел саен тез һәм оча сөяге буыннарын алыштыру буенча меңнән артык операция ясала. Аны көтү вакыты – бер елга кадәр.

kzn.ru

COVID-19

Көзгә хәстәрне бүгеннән күрәсе

Коронавирус белән бәйле вазгыять күпмедер дәрәҗәдә тотрыкланса да, тынычланырга иртәрәк. Татарстанның сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков журналистлар белән очрашуда шулай дип кисәтте.

«Без үзебезне шушы чирнең нәрсә икәнен дә белмичә яшәлгән 2018–2019 еллардагы кебек иркен тотарга тиеш түгел. Коронавируска каршы вакцина ясату мәсьәләсе дә актуаль булып кала бирә. Бүген 2546284 кеше – бу вакцинаның беренче, 2223658кеше икенче компонентын ясаткан», – ди белгеч. Республикада балалар өчен кайтарылган вакцинаның да 96,2 проценты ясалган.

Билгеле булганча, 60 яшьтән узган кешеләр коронавирусны авыррак кичерә. Алар арасында чирдән соң өзлегүләр, үлем-китем очраклары да күбрәк күзәтелә. «Шуңа күрә коронавируска каршы вакцина ясату 60тан узган кешеләргә аеруча киңәш ителә», – диде министр урынбасары.

Бүген бу төркемгә кергән 649000 кеше – коронавируска каршы вакцинаның беренче компонентын, 447000 кеше икенчесен ясаткан. Бу – яше 60тан узганнарның 76 проценты ковидка каршы вакцина ясаткан дигән сүз. Владимир Жаворонков вакцинаны ярты ел элек ясаткан кешеләргә ревакцинация узар, ягъни коронавируска каршы вакцинаны яңадан ясатыр чак җиткәнне дә искәртте. Белгеч бу эшне сузмаска киңәш итте. Ник дигәндә, вакцинаның вакыты чыгуга, чир йоктыру куркынычы да арта. Биредә узган елның 26 ноябренә кадәр вакцина ясаткан кешеләр турында сүз бара.

Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсе башлыгы урынбасары Любовь Авдонина көзгә таба коронавирус белән авыручылар саны яңадан артырга мөмкин дип фаразлый. «Коронавирус та сезонлы чиргә әверелеп бара. Бу очракта да чирнең күтәрелгән, кимегән чорлары була. Көзгә таба вируслы авырулар баш калкыта. Шуңа күрә бу чорда коронавирус белән авыручылар саны артачагына да әзер торырга кирәк. Саклык чараларын күрмәсәк, вакцина ясатмасак, хәлләр мөшкел булачак», – ди белгеч.

Узган тәүлектә Татарстанда коронавирусның 139 яңа очрагы ачыкланган. Шул рәвешле республикада барлыгы 149579 ковид йоктыру очрагы теркәлгән. Авдонина сүзләренә караганда, ковид йоктыручылар саны 21 февральдән соң кими башлаган. Хәзерге вакытта республикада «омикрон» штаммының 1262 очрагы теркәлгән. Бу – теркәлгән барлык коронавирус очракларының 95 проценты шушы штаммга туры килә дигән сүз. Тормышыбызда коронавирус пәйда булганнан бирле Татарстанда аны ачыклау өчен барлыгы 6426000 пцр-тест тапшырылган.

Роспотребнадзор идарәсе белгечләре төрле оешма, объектларда коронавирусны кисәтү таләпләренең үтәлү-үтәлмәвен дә контрольдә тота. Соңгы бер атна эчендә алар шундый 99 оешмада тикшерү уздырып, шуларның 47сенә беркетмә төзегән.

Владимир Жаворонков сүзләренә караганда, бүген республикада вакытлыча ачылган 18 ковид-госпиталь эшли. «Бу саннан куркырга кирәкми. Алар халыкка тиз арада ярдәм күрсәтү өчен кирәк. Республиканың ерак районында яшәгән кешене, өч-дүрт сәгатьлек юл узып, башкалага алып килеп йөрмичә, үзләрендә генә ярдәм итә алсыннар өчен ачылды бу госпитальләр. Аларда ятак урыннар саны да җитәрлек», – ди министр урынбасары.

Исегезгә төшерәбез: бүген башкалада өч ковид госпитале эшли. Аларның берсе – Казанның йогышлы авырулар хастаханәсендә, икенчесе 7 нче номерлы шәһәр хастаханәсендә урнашкан. Коронавирус йоктырган балаларны исә Республика клиник балалар хастаханәсендә кабул итәләр.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

Алексей ПУШКОВ, Федерация советы вәкиле:

Без Россиянең глобаль интернеттан чыгарылуына әзер булырга тиеш. Хәзергә Көнбатыш бу акциянең уңай һәм тискәре якларына бәя бирү белән мәшгуль. Әгәр әлеге адымга барса, Россия үзенең мәгълүмат киңлегендә кайнарга мәҗбүр булачак һәм безгә Көнбатыш йогынтысы сизелерлек кимеячәк.

(Россия төбәкләре палатасында узган «Түгәрәк өстәл»дә ясаган чыгышыннан)

РОССИЯДӘ – КИТАП УКУ

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре Россиядә халыкның китапка карата мөнәсәбәтен сорашкан. Гомумән алганда, ил халкының 92 проценты китап укырга ярата икән.



Кәгазь китап укыйбыз..........58%

Гаджеттан укыйбыз.............35%

Компьютердан укыйбыз.......10%

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ



Наил ШӘРИФУЛЛИН

Упкын сиңа караса...

Киеренке яшәешнең дүртенче ае китте. Әле һаман да яңалыклар тасмасын карарга курыккан вакытлар була. Кайчагында гомумән дә урманга качып, берни белми, ишетми яшисе килә. Күңел тынычлыгын урлаган кайнар фазаны әйткән дә юк, чүп өстенә чүмәлә, дигәндәй, ярсу мәгълүмат бәрелешләре, мәгълүмат сырын тутырган меңәрләгән фейклар, узара гаепләүләр, янаулар, төрле вазыйфаи затларның белдерүләре бимаза тудыра. Җанны иң өшеткәне – әлбәттә инде, төрле илләрдәге, төрле рангтагы җитәкчеләр, белгечләр авызыннан атом-төш коралы куллану-кулланмау мәсьәләсенә, аның шартлары, сәбәпләре хакында ишетеләгән сүзләр.

Атом бомбасы дигәндә, кешелекне мин кайчак граната белән уйнаучы маймыл итеп күз алдына китерәм. Бит алкасын гына тартып чыгарасы. Зиһенең ярты-йорты икән, ялгышып та, махсус та, уйнап та тартып алып була аны. Ә аннан соң... Аннан соң билгеле. «Кешелек эволюциясендә эволюция күп микән?» – дигән сорау туа. Акыл дефициты булганда, уйлар рациональ, ипле булмаганда, агрессия ташыганда, гомумән, эволюция хакында сүз куерту урынлы микән? Ул сүз бит алгарышны аңлата. Кайда монда алгарыш? Адәми затның атом коралын уйлап табарга аз гына да хакы юк иде. Аның әле дары уйлап табарга да хакы булмагандыр. Анысы да – үтерү коралын камилләштерү бит. Дары фейерверк ясау ау мылтыгы гына түгел, ул – пуля янгыры яудыручы пулемет та, коточкыч җимергеч көчкә ия гаубица да, танк та. Ракны җиңә алмаганнарның үтерү коралын аның саен яхшыртып торырга, аның саен яңаларын, әшәкерәкләрен тудырырга әхлакый хакы юк иде. Тик тудырлар, хәтта ки кулланалар да. Дистәләрчә мең кешене берьюлы юк итәргә сәләтле супербомбаны да ясарга үк кулландылар. Хәтәр коралны сугыш беткәч үк тыясы урында, аны күпләп җитештерү, аның саны, куәте буенча ярыш башланды. Бер дәүләтнең икенчесенә шуны тәбәп куюы, куркытулар, тагын да ашкынып камил коралларга китте. «Болай кыланып, без кая барабыз?» – дип сораучы, сорауга җавап эзләүче генә булмады.

Нәрсә ул атом сугышы? Ул – кешелекнең үз-үзен үтерүе. Өлкән туган теле белән әйткәндә, ул – «коллективное самоубийство», апокалипсис. Без әле янарак кына пандемияне глобаль куркыныч итеп күрә идек. Бүген аны оныттык. Ул бүгенге халләрдә томаудан да кайтышрак вак-төяк булып калды. Атом сугышы ихтималын – барыбызны да йотарга сәләтле упкынны җыйнаулашып күмәсе, яисә киртәләп аласы урында, без дуамалланып, упкынның кырыена якынлашабыз, бер-берсебезгә усал сүзләр атабыз, яныйбыз, һаман да әтәчләнәбез.

Сезнең упкынга караганыгыз бармы? Яки биек кыя башыннан аска? Андый очракларда күпләр ниндидер көчнең сине аска тартуын, хәтта чакыруын искәрә. Үзем белән дә шулай булганы бар. Без упкынга соңгы арада ешрак карый башладык. Халыкара конфликтларны, ихтималлыгы көчәйгән атом-төш гарасатын андый карау-ашкынуда бердәнбер сәбәп, дип әйтеп булмый. Аннан башкалары да бар. Җирдә, дөрес тормыш кора белмәү аркасында, кешенең яшәү көчен, теләген киметә торган куркыныч шартлар барлыкка килде. «Бәрәкәтле дөнья» дип аталган тарафларда, ягъни алга киткән илләрдә яшәүнең кызыгы азаю турында электән язып киләләр. Мәсәлән, хәтсездән «коммунизм»да яшәгән, бөтен планетада тормыш сыйфаты иң югары саналган Төньяк Европа илләрендә үз-үзләренә кул салучыларның башка дәүләтләрдәгедән күбрәк булуы билгеле.

Ягъни тормышның артык бөтен, тамакның үтә дә тук булуы яхшыга түгел, дигән парадоксаль нәтиҗә чыга. Куллану җәмгыяте бу яктан алганда – тозак. Чөнки тормыштан көрәш китә, мотивация югала. Рәхәтлекләрдән адәми зат мәлҗеры, тонусын югалта. Әйбер җыю, үзеңне уңайлыклар белән урау ул, әйбәттә инде, көрәш була алмый. Ул – идән астындагы тычкан чабышы кебек примитив әйбер. Популяциядә табигый сайланыш булмау да үз йогынтысын һәрдаим белгертеп тора: тәне чирлеләр генә түгел, рухи сырхаулар саны да күбәя.

Яңадан барыбызны да упкын кырыена терәргә тырышучы төп факторга – кешеләр бер-берсен юк итәр өчен тырышып ясаган коралларга, аларның иң хәтәре булган атом бомбасына, аның кулланылу мөмкинлегенә кайтыйк. Бүгенге дөньяның тугыз иле шул дәһшәтле коралга ия. Барыбыз да белгән бишлектән (АКШ, Россия, Кытай, Англия, Франция) тыш, тагын бер-берсе белән тыныша алмаган Һиндстан белән Пакьстан, шулай ук Израиль һәм Төньяк Кореяда бар ул иблис коралы. Җирдәге иң җимергеч корал берәмлекләрен (боеголовкаларны) бергә кушып исәпләгәндә, һуш китмәле зур саннар чыга. Аларның күбесен 1945 елда Америка һава көчләре Хиросимага ташлаган бомба белән чагыштырырлык, якын куәтлек та түгел. Араларында җимеру, юк итү сәләте беренче бомбадан йөз, хәтта мең тапкыр зуррак булганнары да бар. Шуңа күрә: «Без барыбыз да дары мичкәсе өстендә яшибез», – дигән сүздә арттыру юк...

Кайбер галимнәр антропосфера дип аталган, кеше яшәгән тирәлектәге эфирның аның коллектив «эго»сы, мин-минлеге, агрессиясе белән тулышкан булуын билгелә. Тик аннан нинек котылырга кирәклеген белми. Начар энергия белән мөлдерәмә тулы ул эфир нәкъ менә без искәрткән упкын инде. Килбәтсез, мәгънәсез гамәлләребезне арттыра-арттыра упкынга карыйбыз, упкын да безгә карый. Аның безгә каравы күпкә хәтәррәк. Кара энергиянең куәмә критик чиккә җиттеме, бернигә дә карамастан, упкын безне үзенә суырып алачак. Галәмдәге үзенә якынайган барлык күк җисемнәрен чайнәмичә йотып, ул материяне юка элпә итеп үз өслегенә сылап баручы, коточкыч тарту көченә ия «кара тишек»ләр («черная дыра») кебек. Бу инде – бетү, ахырзаман дигән сүз. Һәм аны бөтенләй үк гаделсез дип тә атап булмыйдыр. Рас Җирдә бер-берең белән тынышып, гармониядә, дуслыкта яши белмисең икән, яшәп тә маташма, дигән сүз ул.

Кеше токымына якын киләчәктә ике генә вариант каралган. Йә акылыбызга килеп, туктыйбыз, килешеп яшәп, Җирдәге үзара дошманлыкны бетерәбез, йә үзебездән соң үле планета калдырып, юкка чыгабыз. Өченче юл юк.

ҮЗЕҢНЕКЕ – ҮЗӘКТӘ

Кичә республиканың Хөкүмәт йортында нефть тармагы оешмалары җитәкчеләре белән утырышларда сүз йомгагы әнә шуңа барып тоташты. Киңәшмәләрне Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов уздырды.

Максатлар билгеле

Социаль үсешкә ярдәм итү, нәтиҗәле хезмәт өчен шартлар тудыру, тирә-юньгә тискәре йогынтыны киметү, түбән углеродлы икътисадка күчү, технологияләрне үстерү... «Татнефть» оешмасы тотрыклы үсеш тәэмин итүдә әнә шул максатларга таяна. Бу хакта оешманың Директорлар советы утырышында искәртеләр.

Киңәшмәдә «Татнефть» оешмасының тотрыклы үсеш һәм кызыксынган яклар белән хезмәттәшлек өлкәсендәге сәясәте расланды. Оешма бу юнәлештә закон тарафыннан билгеләнгән барлык таләпләрне үтәү, Конституция нигезендә кеше хокукларын саклап эш итүне дә күздә тота.

Үзеңнеке кирәк

«Татнефтехиминвест»ның Директорлар советы утырышында Президентка берничә кызыклы проект тәкъдим иттеләр. Аерым алганда, Мәскәүнең органик химия институтының лаборатория мөдире Александр Стахеев газ калдыкларын азот оксидыннан чистарту өчен үзебездә сәнәгый катализаторлар җитештерү турында сөйләде. Белгеч сүзләренә караганда, ягулык якканда, ягулык электростанциясе, металл, нефть эшкәрту заводы кебек оешмаларда эш барышында азот оксиды буленеп чыга. Бу исә, үз чиратында, әйләнә-тирәгә дә, кеше сәламәтлегенә дә тискәре йогынты ясый.

«Азот оксидын юкка чыгаручы катализаторларны Германия, АКШ, Бөекбритания, Япония, Дания җитештерә. Хәзер алар барысы да Россия белән хезмәттәшлекне өзде. Кытай оешмалары да бар, әмма алар белән дә проблемалар килеп чыга. Үзебезнең катализатор кирәк», – диде Стахеев.

Бу фикер Рөстәм Миңнехановта да кызыксыну уятты. Ул оешмаларга бу тәкъдимне исәпкә алырга кушты.

– Читтән кертергә ирек бирмәсәләр, үзебезгә эшләргә туры киләчәк. Безгә бик күп төрле импорт алмаштыру программалары эшли. Моны да эшләсәк, безгә берниндн санкцияләр дә куркыныч булмаячак. Бар нәрсәне дә үзебездә җитештерергә өйрәнергә кирәк, – диде Президент.

Рөстәм Миңнеханов Санкт-Петербургның «Балтмаш» оешмасы вәкиле Руслан Крыловның тәкъдимен дә игътибарсыз калдырмады. Ул сыекландырылган газ саклау өчен материаллар җитештерү турында сөйләде. «Безгә мондый җылылык саклаучы материаллар кирәк, кызыклы тема», – диде Президент. Ул җирле нефть химиясе оешмаларына булачак җитештерү өчен чимал кайтарту ягын кайгыртырга кушты.

Катлаулы нефть калдыкларын эшкәртү, оешмалар өчен сәнәгый тузан суырткыч проектлары да тәкъдим ителде.

«Кара алтын» турында

Быелның беренче кварталында Россиядә 135 миллион тонна нефть чыгарылган. Бу, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, 8 процентка күбрәк. Бу хакта республиканың кече нефть оешмалары белән узган утырышта Рөстәм Миңнеханов хәбәр итте. Бу чорда Татарстанда барлыгы 8,7 миллион тонна нефть чыгарылган.

– Беренче квартал нәтиҗәләрен без глобаль, системалы үзгәрешләр шартларында ясыйбыз. Дөнья күләмендәге вазгыять, Россиягә каршы нефть эмбаргосы кертү турында сөйләшүләр базарда билгесезлек артуга китерде. Нәтиҗәдә без нефть котировкаларының артуын күрәбез. Аның бер барреле 110 долларга җитте, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Ростехнадзорның Идел буе идарәсе башлыгы Азат Мөбарәкшин сүзләренә караганда, бүген оешма 31 кече нефть компаниясенә күзәтчелек итә. Ул март аеннан башлап илдә планы тикшерүләргә мораторий кертелүен дә искәртте. «Шуңа күрә Ростехнадзор белгечләре беренче, икенче класс куркынычлы объектларны тикшерүен дәвам иттерәчәк», – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов житештерүнең өзлексез эшләве өчен җитәкчеләрнең җаваплы булуын искәртте.

«Нефтеконсорциум» оешмасы генераль директорының беренче урынбасары Олег Вышенский сүзләренә караганда, агымдагы елның беренче кварталында республиканың кече нефть оешмалары 74,1 миллиард сумлык продукция җитештергән. Бу агымдагы елның шул ук чоры белән чагыштырганда 54 процентка күбрәк. Шушы вакыт эчендә 74 яңа скважина кулланылышка тапшырылган.

Олег Вышенский республиканың кече нефть табу оешмалары оешуга быел 25 ел тулганлыгын да искәртте. Шул вакыт эчендә 8 меңгә якын эш урыны булдырылган. Республиканың кече нефть табу оешмалары ел саен 7 миллион тоннадан артык «кара алтын» чыгара.

ХИМИКЛАР БӘЙРӘМ ИТӘ

Татарстан Премьер-министры Алексей ПЕСОШИН фармацевтика, химия һәм нефть химиясе сәнәгате хезмәткәрләрен һөнәри бәйрәмнәре белән котлады.

«Татарстан илнең икътисади үсешен тәэмин итәрдәй данлыклы традицияләргә һәм сәнәгатьтә зур мөмкинлекләргә ия. Республиканың фармацевтика, нефть эшкәрту, химия һәм нефть химиясе сәнәгате предприятиеләренең байтагы, Европа һәм Россиядә иң зур предприятиеләр буларак, көндәлеккә сәләтле продукция төрләрен чыгаруны дәвам итә, авыл хуҗалыгыннан алып, хәрби-сәнәгать комплексына кадәр, икътисадның барлык тармаклары белән элемтәләрне ныгыта. Тармакның тел-теш тидергесез эшләве югары квалификацияле меңнәрчә белгечнең көндәлек тырыш хезмәтенә, һөнәргә тугрылыгына, эшкә җитди карашына һәм югары дәрәҗәдә оешканлыгына бәйле.

Бүген Россия сәнәгате катлаулы чор кичерә. Бездән, шул исәптән республиканың химия предприятиеләреннән үзгәрешләр таләп ителә. Мөмкинлекләр чоры да әле бу. Химия предприятиеләре акционерларының, хезмәткәрләре һәм фәнни учреждениеләренең уртак эше нәтиҗәсендә кыска гына вакыт эчендә сәнәгать, халык өчен кирәкле производствоолар җәйга салына.

Илебез сәнәгатен төрле яклап үстерү, инновацион проектларны гамәлгә ашыру, һичшиксез, муллыкны, икътисади иминлекне артыруны, килачәк буыннарның лаеклы тормышын тәэмин итә.

Фармацевтика, химия һәм нефть химиясе сәнәгате, шулай ук тармакның фәнни учреждениеләре хезмәткәрләренә югары дәрәҗәдәге профессиональлеге, үзләре сайлап алган эшчәнлек өлкәсендә даими рәвештә камиллеккә омтылулары өчен эчкерсез рәхмәт!

Тармак ветераннарына аерым рәхмәтләремне җиткерәсем килә. Татарстан Республикасында химия тармагы өлкәсенә керткән өлешегез бәяләп бетергесез зур! Бүген сезнең күбегез яшь белгечләрнең остазы булып тора, ә бу – традицияләрне, уникаль тәҗрибәне саклау нигезе», – диелә котлауда.

ХЕЗМӘТЕНӘ КҮРӘ – ХӨРМӘТЕ

Химиклар көне

Түбән Кама – Татарстанның химиклар башкаласы. Шуңа да соңгы ун елда Химиклар көне бирегә уздырыла. Бәйрәмнең «Нефтехим Арена» боз сараенда үткән тантаналы өлешендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, СИБУР компаниясе генераль директоры Михаил Карисалов, башка рәсми затлар һәм республикабызның нефть, газ, химия тармагы предприятиеләрендә эшләүчеләр катнашты.

Быелгы бәйрәмнең үзенчәлеге шунда: ул беренче тапкыр СИБУР форматында оештырылды. Исеме дә шуңа авазаш: «СИБУР. История в лицах». Бу гадәти генә тамаша түгел, ә боз өстендәге шоу иде. Башкаручылары да гади түгел – Олимпия чемпионнары. Ә Химиклар көне «Түбән Кама Нефтехим» җәмгыятенең юбилее – беренче продукция алынуга 55 ел тулуга багышланды.

– Ике «бишле». Ул мәктәп укучысы өчен иншаны тирән эчтәлекле һәм хатасыз язуны аңлатыр иде, ә бездән очракта беренче «5ле» – фидакарь хезмәт һәм югары сыйфат өчен булса, икенчесе – хезмәт коллективына бирелгән бәя, – диде «Түбән Кама Нефтехим» җәмгыяте генераль директоры Айрат Сафин.

Кеше холкы белән шундый: бәйрәмгә килучеләр арасыннан таныш йөз эзли. Бүген хезмәт урыным башка оешмада булса да, утыз елга якын хезмәт куйган коллектив сагындыра. Шуңа да тамашачы арасында танышларны күрү үзе бер вакыйгага тиң. Сөйләшер сүзләр күп.

Елдагыча, тантанага компания ветераннарын да чакырлар. Өлкән буын заман шартларына яраклашып яши бүген: һәрберсенең кулында шәп телефон, бер-берсен фотога төшерәләр. Ә өңгәмәләре – яшьлекләре белән үрелеп барган хезмәт еллары хакында. «Хәтерлисеңме, – дип башланып киткән сүз, бөтерелә-бөтерелә: – ...иде бит», – белән тәмамлана.

Каршыма кул болгап килучегә җавап итеп, мин дә кул изим. Якташым, Арча районының Яңа Кенәр авылы егете Рузил Мингалиев икән. Бер уңайдан әйтеп китим: Рузил җитәкләгән коллектив компаниянең икенче сәнәгать зонасындагы заводларның технологик җиһазлары төзеклеге, тотрыклы эше өчен җаваплы.

Бу көнне бүләкләнүчеләр арасында KAMA TYRES «Түбән Кама шин» җәмгыяте вулканлаштыручысы Анатолий Матросов та бар. Ул да хезмәт биографиясен бер коллектив белән бәйләгән. «Әле кичә генә завод территориясенә беренче тапкыр аяк атлап кергән идем кебек, баксаң, кырык ел узган да киткән! Без житештергән шиннарның Җир шары юлларын иңләве горурлык түгелме?!» – ди ул. Үзен гади эшче дип атаса да, цехның хезмәт күрсәткечләрен күтәрүдә аның да өлеше бар. Әйтик, хезмәтне саклау, җитештерү чыгымнарын, югалтуларны киметү юнәлешендәге тәкъдимнәре уңышлы кулланыла. Бу көнне ул һәм йөк шиннары заводында эшләүче коллегасы Евгений Мельников «Республиканың атказанган химигы» исеменә лаек булды.

Химиклар көне иртәнге якта «Түбән Кама Нефтехим» җәмгыятенең беренче генераль директоры Н.В. Лемаев һәйкәленә чәчәк бәйләмнәре кую белән башланып, Нефтехимиклар паркында оештырылган күңел ачу чаралары, шул исәптән Олег Газманов чыгышы белән дәвам итте, ә соңгы ноктасы шәһәр күгенә төрле төсләр белән янкытуучы бәйрәм салюты булды.

Нурисә ГАБДУЛЛИНА

Илдар Мөхәммәтҗанов

Казанда Татарстанның беренче Премьер-министры Мөхәммәт Сабиров истәлегенә мемориаль такта ачылды. Аны ул 1995–2015 елларда Чехов урамында яшәгән йорт диварына урнаштырдылар. Тантанада Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Премьер-министрның беренче урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин, депутатлар, Мөхәммәт Сабировның якыннары катнашты.

Фәрит Мөхәммәтшин Мөхәммәт Сабировны һәрвакыт үз фикерендә торган кеше буларак искә алды. Аның яңа шартларда республика тормышын җайга салуда, федераль үзәк белән мөнәсәбәтләр коруда башкарган нәтиҗәле хезмәте, депутат буларак парламент эшчәнлегенә керткән өлеше турында сөйләде. «Безнең республиканың көче күпмилләтле халкыбыз һәм туган Татарстан үсешенә үз өлеш керткән кешеләр турында саклаган истәлектән гыйбарәт. Без бу традицияләрне буыннан-буынга тапшырабыз, шул рәвешле яшьләрне тәрбиялибез», – диде Дәүләт Советы Рәисе.

Мөхәммәт Сабиров 2015 елда Казанда вафат булды. Быел март аенда аңа 90 яшь тулган булыр иде.

БАШКАЛАРДАН КИМ ТҮГЕЛ

БЕЛГЕЧЛӘР КОРБАНЛЫК МАЛНЫ САЙЛАГАНДА САК БУЛЫРГА КИҢӘШ ИТӘ

Быел Корбан гаете 9 июльгә туры килә. Корбанга дигән сарыклар республикага 1,5 ай алдан кертелү сәбәпле, җаваплы органнар куркынычсызлык мәсьәләләрен алдан кайгырта башлый.

Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары Габделхак Мотыйгуллин әйтүенчә, күпләп сарык үрчетү белән шөгыльләнүче күрше төбәкләрдә йогышлы авырулар буенча вазгыять катлаулы. Аларда тилчә, бруцеллез, сарыкларда чәчәк кебек куркыныч авыру очраклары теркәлгән.

– Әлеге авырулар хайваннар өчен генә түгел, кешеләр өчен дә куркыныч. Шуңа күрә без, аларны үзебезгә кертмәс өчен, бар көчне куябыз. Татарстан әлеге авырулар ягыннан имин. Шунлыктан бездә аларга каршы прививка да ясамыйлар. Бәйрәмгә диган сарыкларны исә үзебезнең эшмәкәрләрдән сатып алырга киңәш итәбез. Алар читтән кертелгәннәрдән бер дә калышмый, – дип аңлатты Габделхак Мотыйгуллин.

Аның сүзләренчә, республикада сарык үрчетү белән шөгыльләнүчеләр шактый. Мәсәлән, Әтнә, Питрәч, Саба, Арча районнарында корбанлык терлек үрчетү белән махсус шөгыльләнүчеләр бар.

– Аларның сарыклары сау-сәламәт, матур. Үзләре дә дин юлында, алдалап сатмыйлар, – ди ул. – Сыйфаты да яхшы булган сарыкны эзләп йөрергә кирәк булачак, дигән фикер калмасын иде.

Малларны читтән алып кергән очракта да, ветеринария идарәсеннән һичшиксез рөхсәт алырга туры киләчәк. Белгеч, һәр малның ветеринария документы булырга тиешлегенә басым ясады.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Алып кайткан маллар карантинга ябыла. Шушы вакыт эчендә авыруларның беренче билгеләре күзәтелә башларга мөмкин. Узган ел корбанлык сарыкларны бары тик Чувашиядән генә алып керделәр, – диде Габделхак Мотыйгуллин.

Белгечләр әйтүенчә, корбан чалырга теләк белдерүчеләр саны елдан-ел арта. Галбелхак Мотыйгуллин узган ел республиканың рәсми мәйданчыкларында 15 меңгә якын корбан чалынганлыгын әйтте. Татарстан Диния нәзарәтенең Үзәк ревизия комиссиясе рәисе Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин сүзләре буенча, быел республикада Корбан бәйрәме көннәрендә 17 меңнән артык корбан чалыныр дип фаразлана.

– Республика буенча 50–60 баш мөгезле эре терлек чалыныр, мөгаен. Төгәл саннары Корбан гаетеннән соң күребез. Халык пандемиядән соң рамазан аенда бик активлашты, – диде Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин.

Аеруча Казан, Яшел Үзән, Әлмәт, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләре халкы активлык күрсәтә икән.

Хәзрәт китергән мәгълүматларга караганда, быел республика буенча – 51, Казанда 18 мәйданчыкта корбан чалыначак.

– Әлеге урыннарда имам-мөхтәсибләребез хезмәт куя. Кешенең корбан чаласы, яки корбанны чалдырасы, аның тәртипләрен беләсе килә икән, мәчетләрнең имам-хатыйбларына мөрәҗәгать итеп, мәгълүматны алардан алырга мөмкин, – диде ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Корбан чалырга әзерләнгәндә истә тотарга кирәк:

- корбанга чалыначак мал сау-сәламәт булырга тиеш. Аяклары, колаклары киселмәгән булу дөрес санала;
- яше җитлеккән булырга тиеш;
- корбанга чалыначак терлекне сатып алганда, сатулашу рөхсәт ителә;
- корбан чалырга алдан әзерләнү – күркәм гадәт. Моның өчен йорт янындагы мәчеткә керөп, хәзрәтләр белән киңәшләшергә кирәк;
- корбанны өч көн дәвамында чалырга мөмкин.

ТУЛА САМАВЫРЫ БЕРЛӘШТЕРӘ

ШӘҖӘРӘ

«Ватаным Татарстан» газетасы һәм Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының уртак проекты

Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты үткәргән «Шәҗәрә» фестивале җиңүчеләрне билгеләде. Арча педучилищесында бер чорда укыган сабакташларым Гөлнирә белән Рәис Нәгыймуллиннар, кода-кодагыйлары Латыйповлар белән бергәләп, Татарстан буенча икенче урынны яуладылар. Бүген бу ике гаилә туган якларында – Буа районында яши.

Нәсел агачы

Сабакташларым укуда да гел алдынгы булдылар, сәхнәдән дә төшмәделәр, музыка коралларын да үз иттеләр, спортта да сынатмадылар. Димәк, гаилә коргач та тормышларын шул рәвешле дәвам иткәннәр дип уйларга кала. Алма агачыннан ерак төшми, диюләре хак икән. Балалары да үзләре кебек.

– «Шәҗәрә» дигән сүзне әби-бабайлардан еш ишетергә туры килде безгә, – дип сөйли кызлары Ләйлә. – Аның туганлык җепләрен бәйләп торучы истәлек икәнен кайберәүләр белеп тә бетермидер әле. Ул яктан мин бәхетле. Әнием мәктәптә тарих дәресләре укытты. Укучыларга бу хакта гел тәфсилләп аңлата иде. Нәсел агачын барлау эше йортыбызда мин бәләкәй чакта ук башланды. Әтиәнием, Мөния әбием һәм туганыбыз Нурулла абый башта Рәхмәтулла исемле ерак бабамнан калган шәҗәрәне иске имлядан кириллицага күчереп яздылар. Ул китап формасында эшләнгән иде. Шушы язмаларга таянып, алар «Чәчкап авылы – ата-баба нигезе» дип исемләнгән китап бастырып чыгардылар.

Сүз дә юк, китап бастырдылар дип әйтү генә җиңел. Аңа кадәр Рәис белән Гөлнирә, һәр йортка кереп, авыл кешеләре турында мәгълүмат җыялар. Архив тузанына батып, метрика кәгазьләрен, ревизские сказки кебек документларны өйрәнәләр. «Шәҗәрә» фестивале дә үз эшен эшли, этәргеч бирә: соңрак Ләйләдә дә әти-әнисе туплаган документларны тулыландырасы килү теләге уяна. Ире Ильяс нәселе белән дә кызыксына башлый. Ике яклап һәр гаилә әгъзасы үз өлешен кертә. Нәсел агачының тамырлары ныгый, ябалдашлары куера бара. Шуңа күрә улы Рөстәм белән кызы Наиләгә барып тоташкан шәҗәрә агачы фестивальдә зур бәя алган да инде.

– Нурулла абый архивларда эзләнгәндә, Рәхмәтулла бабамның Чәчкап авылына килеп урнашканлыгын раслаучы язуны эзләп таба, – ди ул. – Аның күчермәсен безгә дә калдыра. Нәгыймуллиннар гаиләсендә энем Рамилнең улы Рахманга кадәр 17 буынны санап чыктык. Ә Латыйповларда улым Рөстәмгә кадәр 12 буын билгеле. Иң кызыгы шунда: эзләнә торгач, ике нәселнең туганнар булуы да ачыкланды. Тарихка күз салсак, Иске Чәчкаптан Яңа Чәчкапка килеп урнашкан өч буын (Мыек, Кылый һәм Бүре) – барысы да Латыйповлар нәселеннән. Ә минем дәү әбием Фатыйма (бабам Нәгыймулла хатыны) үзе дә шушы Бүре нәселенә барып тоташа. Әтием чыгарган китапта да әбиемнең кайсы йортта яшәгәнлеге һәм Нәҗметдин кызы булуы язылган. Һәр ике гаиләдә дә дин әһелләре, авылда һәм тирә-якта мулла вазыйфасын башкарып, халыкка хезмәт итүчеләр булуын да белдек.

Укытучылар

– Аң-белемле булу шулай ук буыннан-буынга дәвам иткән. Хәтта санап та бетерерлек түгел. Әтием-әнием, дәү әтием, дәү әнием, әтиемнең абыйсы Фирдүс, аның хәләл җефете Әлфинур, әниемнең әнисе Мәдинә, апасы Альмира, кызы-киявләре, энем Рамил, сеңлем Гүзәл, мин үзем – барыбыз да укытучылар, тәрбиячеләр, – ди Ләйлә.

Рәиснең әтисе Сабирулла яшьли ятим кала. Энесеңелләрен тәрбияләү өчен 20 яшендә өйләнә ул. «Әнисенең васыятен үтәде, туганнарын үз балалары кебек үстерде», – дип искә ала соңыннан хәләле Мөния апа. Тик авырлыклар көтеп кенә тора егетне. 1949 елның 2 гыйнварында өйләнеп, 20сендә армиягә китеп бара. Алты айдан авырып кайта. Шулай да сугыш елларында 11–12 яшеннән колхоз эшләрендә чыныккан егет аптырап калмый: көтү көтәргә чыга, балта остасы булып та эшли. Кулыннан бар эш тә килә аның. Шуңадыр инде, соңрак мәктәптә хезмәт дәресләре укыта башлый. Черкен авылында туып үскән Мөниясе дә шунда. Гомер буена башлангыч сыйныф укытучысы. Уллары икесе дә физика һәм математика факультетын тәмамлый. Рәис педучилищеда белем алып кайткач, йортка – яңа көч, Гөлнирә килен булып төшкәч, яктылык, җылылык иңә. Мөния апаның бу хакта сөйләгәннәре дә видеоархивта саклана. Безнең гаиләгә бәхет алып килгән бала ул, ди Мөния ханым килене турында. Балалары да бик рәхмәтле үзенә. Икесе дә читтән торып югары уку йортын тәмамлыйлар. Беренче онык туу белән әниләре бала карарга дип пенсиягә чыга. «Йортны, балаларны карау, ашарга пешерү өстенә әни эшебездә дә ярдәм итте. Без кайтканчы программа буенча «Совет мәктәбе» журналларына кадәр эзләп табып куя иде. Үзе укытучы булып эшләгәч, хезмәтебезнең бөтен нечкәлекләрен белә иде шул. Олы кеше тәрбиясе булгач, балалар да бик тәртипле, тәүфыйклы булып үстеләр», – дип искә ала Гөлнирә.

Сәхнәдә

Фестивальдә җиңү яулау өчен сәхнәне дә дер селкетергә кирәк бит әле. Бу яктан да кимен куймый Нәгыймуллиннар.

– Авыл, район сәхнәсеннән ерак китмәсәләр дә, әтиәнием, әбием җырлый-җырлый спектакльләрдә катнашалар иде. Ә менә тирәнгәрәк күз салсак, Ситдыйк Айдаров (Рәхмәтуллин) – нәселебездә опера җырчысы, гармунда да оста уйнаган. «Сәйяр» труппасында беренчеләрдән булып «Беренче театр» спектаклендә уйный, Вәли кияү ролен башкара, – дип искә ала Ләйлә. Әтиләренең биш яшеннән тальянда уйнавы, педучилищеда музыкаль белем алуы да эзсез калмый, әлбәттә. Үзе көйләр дә яза, балаларын, оныкларын гармунда, курайда уйнарга өйрәтә. Гармуннарны җыя, төзәтә. Йорттагы бер бәйрәм дә җырсыз-моңсыз узмый, бергәләп концертлар да куябыз, ди Гөлнирә.

...Шулай туры килеп торуын күр әле. Нәгыймуллиннар белән Латыйповлар нәселен берләштерүче тагын бер ядкарь бар икән. Ул да булса – йөз еллык Тула самавыры. Ильясның бабасы Заһид, Ләйләнең ерак бабасы Заһидулланың Бурлы кушаматлы атында чабышларда катнашып, Сембер, Тәтеш өязендә, Казан янындагы төбәкләрдә, Буада беренчелекне яулый. Күп кенә бүләкләргә ия булалар. Ачлык елларында сөлгеләрне һәм башка бүләкләрне икмәккә алыштыралар. Әмма самавырны саклап калалар. Инде күпме еллар үткәч, ике нәсел кабат туганлашыр да шул истәлекле самавырдан чөкердәшә-чөкердәшә чәй эчәр дип кем уйлаган?

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Яңгырасын балачак җыры!

«Шаян ТВ» телеканалы инде өченче ел рәттән балалар өчен яңа җырлар барлау максатыннан «Балачак җыры» бәйгесен оештыра. Быел исә, шушы җырларны тамашачыга җиткерү өчен, концертлар да үткәрә башлаганнар.

Бу эшне алар Татарстан Президенты каршындагы Татар телен, Татарстан халыкларының туган телләрен саклау һәм үстерү мәсьәләләре буенча комиссия һәм Татарстан Дәүләт Советының «Мәрхәмәт» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе белән берлектә башкара. Концертлар Казанның мәдәният йортларында («Мәскәү», «Тимерьюлчылар», «Чулпан», «Сәйдәш» һәм Сәетгалиев исемендәге мәдәни үзәкләрдә) узачак.

«Шаян ТВ» телеканалы баш мөхәррире Рамилә Сәхабетдинова сүзләренчә, концертлар уздыру идеясен Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, комиссия рәисе Марат Әхмәтов тәкъдим иткән. «Әлеге концертларны башлар алдыннан без бик күп уйландык. Нәтиҗәдә «Сәйлән» фестивале җиңүчеләрен дә «эшкә җиктек». Алар сәхнәдән «Балачак җыры»нда җиңү яулаган әсәрләрне яңгыратачак», – дип сөйләде ул.

«Мәрхәмәт» берләшмәсе җитәкчесе Алсу Нәбиева фикеренчә, «Балачак җыры» концертлары гади генә тамаша түгел. «Бу концертларда балалар балаларны тәрбияли. Тамаша залында утырган балалар сәхнәдәге яшьтәшләреннән үрнәк ала, татар телен камилрәк белергә, өйрәнергә омтыла. Балаларыбызга мондый мохит тудыра алуыбыз безне бик сөендерә. Нәтиҗәсе дә яхшы булыр дип уйлыйм», – диде ул матбугат очрашуында.

«Балачак җыры» бәйгесенең жюри әгъзасы Эльмир Низамов әлеге проект балаларда музыкага карата зур кызыксыну уята дигән фикердә. «Бәйгегә килгән кайбер җырларның авторлары – балалар. Аларда без шул рәвешле җырга, музыкага мәхәббәт тәрбияли алабыз икән, киләчәктә мул җимешләр алачакбыз. «Балачак җыры»нда туган җырларның язмышы турында әлегә әйтә алмыйм, ләкин «иң-иң»нәренең «алтын фонд»ыбызга керәчәгенә шигем юк», – диде композитор.

Инде әйтелгәнчә, «Балачак җыры»ның төп миссиясе – балалар җырларына булган кытлыкны бетерү. Бу җәһәттән әлеге бәйгедә җиңгән җырлардан махсус җыентык тупланган. Моннан тыш, аларга заманча аранжировкалар ясала, сыйфатлы клиплар төшерелә. Рамилә Сәхабетдинова сүзләренчә, шул рәвешле яңа җырларга ихтыяҗ мәсьәләсе дә хәл ителә. «Җырларга ясалган аранжировкалар, сүзләре – барысы да безнең рәсми сайтта бар. Без шәһәр мәктәпләре белән генә түгел, районнар белән дә элемтәдә торабыз. Укытучылардан, бу җырлар безгә күптән кирәк иде, күбрәк языгыз, дигән сүзләр, рәхмәт ишетәбез», – диде ул.

«БЕЗНЕҢ ЯШЬЛӘР!» ДИСЕННӘР

Эштә – батырлар, бәйрәмдә – матурлар. Эшләүче яшьләрнең «Безнең заман» иҗат фестивале егет-кызлары әнә шундый. 27–29 майда уза торган слетка да эшсөяр яшь буынның «иң-иң»нәре җыелды. Бу – республиканың әйдәп баручы оешма-предприятиеләрендә эшләүче тырыш хезмәткәрләр генә түгел, иҗатны да тормыш рәвеше итеп сайлап, шуның белән бергә кайнап яшәүчеләр.

bzzm.ru

Сер итеп әйтик: фестиваль кысасында яшьлекнең вакыты озайтыла. Ягъни барыбыз да күнеккән 18–35 яшь кенә түгел, 45 тирәсендә булганнарны да «яшьләр» диләр бирелә.

«Безнең заман» быел юбилеен билгеләп үтә. Аның үткәрелә башлавына 10 ел тулачак. Шушы көннәрдә 10 ел эчендә фестиваль кысасында тәҗрибә туплап, җиңүче дип танылган, Гран-при откан командалар «Волга» үзәгендә ачылган иҗат слетына җыелды. Яшьләр бер-берләре белән тәҗрибә уртаклашачак, мәдәни программада катнашачак. Моннан тыш республиканың танылган сәнгать һәм мәдәният әһелләре аларга осталык дәресләре бирәчәк.

Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы хезмәткәре Алинә Гарифуллина «Безнең заман» хәрәкәтенә әле яңа гына кушылган. «Беренче мәртәбә катнашуым. Безне сайлап алдылар, әлбәттә, каушата. Беренче мәртәбә катнашсак та, үзебезне бары тик яхшы яктан күрсәтергә ниятлибез», – дип уртаклашты ул.

Евгения Насыйбуллина – «Безнең заман»да өченче тапкыр Гран-при откан «Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы» учреждениесе командасы капитаны. Слетка «өлкән иптәш» булалрак килгәннәр, тәҗрибә уртаклашачаклар. «Без белгәннәрне башкаларга бирергә телибез. Шулай ук үзебез дә яраткан остазларыбыздан күп нәрсәгә өйрәнергә дип килдек. Фестиваль ул – иң элек бер-береңә терәк-таяныч, дус булу», – диде Евгения.

Үткән елгыларыннан ким булмас. Фестивальнең генераль продюсеры Дмитрий Туманов сүзләренчә, быел да чарада катнашырга теләүчеләр күп булырга охшап тора. «Быел фестивальнең юбилее. 1200–1400 катнашучы булыр дип көтелә. Бу – республиканың 300ләп предприятиесеннән килгән эшләүче яшьләр дигән сүз. Фестиваль гел үсештә һәм бу куандыра да», – диде ул.

Дмитрий Туманов фикеренчә, хәзерге чорда илнең мәдәни коды, бәхете өчен көрәш бара. «Иң элек рухи кыйммәтләргә, иң кадерле төшенчәләргә каршы сугыш ачылды. Безнең өчен «Ватан», «гаилә», «дуслык» кебек төшенчәләр, традицион кыйммәтләр кадерле. Әхлаксызлык үтеп кермәсен», – диде ул һәм бу фестивальдә катнашучы егет-кызларның да шул сыйфатларга ия булуларына ышануын әйтте.

Шунысын да әйтергә кирәк: «Безнең заман» фестивале – Россия ЮНЕСКО эшләре буенча комиссиясе һәм Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов теләктәшлеге белән үткәрелә.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Хезмәт ветераны **Тимриев** Хәмзә Хәниф улына, **Якушев** Иршат Солтан улына; «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Капиталь төзелеш һәм реконструкция идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы урынбасары **Алтапов** Самат Сәгъдәт улына; «Евростройхолдинг+» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең төзү эшләре җитәкчесе **Садыйков** Инсаф Ришат улына; «Спас районының Спасагрострой предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Хәйруллин** Айрат Наил улына; «Әлмәт-Водоканал» акционерлык җәмгыяте генераль директорының икътисад һәм финанслар буенча урынбасары **Галанова** Ангелина Викторовнага; «Транснефть-Прикамье» акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Галиев** Роберт Әнис улына; «Алойл» ябык акционерлык җәмгыятенең 1 номерлы нефть промыселы идарә пульты операторы **Хәбипова** Светлана Әнвәр кызына; «Алойл» ябык акционерлык җәмгыятенең технологик компрессорлар машинисты **Хисаметдинов** Замир Минбай улына; Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Алабуга районы һәм Алабуга шәһәре территориаль бүлекчәсе җитәкчесе **Гончар** Ольга Никоноровнага; «Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең машиналар эксплуатацияләү һәм төзекләндерү кафедрасы доценты **Медведев** Владимир Михайловичка; Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасы рәисе урынбасары **Миргасыймова** Илүзә Мөстәкыйм кызына; «Дәүләт гамәли оптика институты» фәнни-җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыятенең сынау заводы җыю-радиомонтаж цехының механика җыю эшләре слесаре **Порохов** Дмитрий Николаевичка; Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының проект эшчәнлеге һәм илкүләм проектларны гамәлгә ашыруны координацияләү бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Гайнетдинова** Светлана Анатольевнага; Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының проект эшчәнлеге һәм илкүләм проектларны гамәлгә ашыруны координацияләү бүлеге башлыгы урынбасары **Горбачева** Елена Николаевнага; Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы урынбасары **Галәүтдинов** Артём Илдархан улына; Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе коммерциячел булмаган оешмалар эшләре бүлеге баш белгече – эксперты **Гафарова** Мария Матвеевнага; «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлеген контрольдә тоту һәм проблемалы объектларны мониторинглау бүлеге башлыгы **Гыйльфанов** Руслан Роберт улына; «Төзүче» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директорының хокук мәсьәләләре буенча урынбасары **Донской** Константин Вячеславовичка; «Кукмара районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе директоры **Җиһаншин** Әсхәт Хантимер улына; Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы **Миңнуллина** Лена Әмир кызына; Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шөңшеңәр авыл җирлеге башлыгы **Салихҗанов** Рафил Харис улына; «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениесенең җир һәм мөлкәт мәсьәләләре секторы баш белгече **Сәхәбиева** Рәсүлә Миңнегаян кызына **Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте** белдерелде.

* * *

Республиканың финанс системасын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе **Нуриәхмәтов** Рөстәм Хөсәен улы Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте генераль директоры киңәшчесе **Краснов** Анатолий Васильевич **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«ТАИФ-НК» акционерлык җәмгыяте нефть эшкәртү заводының битум җитештерү цехы технологик җайланмалар операторы **Илюхин** Игорь Аликовичка; «Аммоний» акционерлык җәмгыяте техник контроль бүлегенең беренчел контроль лабораториясе чималга, материалларга һәм сыйфатка беренчел контроль уздыру мастеры **Кирилова** Марина Анатольевнага; «Түбән Кама шин» гавами акционерлык җәмгыятенең вулканлаштыру цехы вулканлаштыручысы **Матросов** Анатолий Николаевичка; «Түбән Кама йөк машиналары шиннары заводы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең вулканлаштыру цехы вулканлаштыручысы **Мельников** Евгений Александровичка; «Түбән Кама нефтехим» гавами акционерлык җәмгыятенең дивинил һәм углеводород чималы заводы дивинил аеру һәм чистарту цехының газ бүлү аппаратчысы **Мөхәмәтшин** Исхак Исмәгыйль улына; «Нәфис Косметикс» акционерлык җәмгыяте – М. Вахитов исемендәге Казан химия комбинаты (Крестовниковларның элеккеге 1 номерлы сабын һәм шәм заводы) синтетик юу чаралары җитештерү заводының чималларны кушу аппаратчысы **Эсенцева** Галина Николаевнага **«Татарстан Республикасының атказанган химигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Нәфис Косметикс» акционерлык җәмгыяте – М.Вахитов исемендәге Казан химия комбинатының (Крестовниковларның элеккеге 1 номерлы сабын ясау һәм шәм заводы) хезмәткәрләре: сыйфат идарәсенең техник контроль бүлеге өлкән химигы **Валькаева** Светлана Рәшит кызына; 3 номерлы цех башлыгы **Каяшева** Марина Александровнага; «Кама-Идел «КВАРТ» резин-техника акционерлык җәмгыяте» акционерлык җәмгыяте хезмәткәрләре: 620 номерлы цехның 101-11 номерлы (307/1, 307/2 участогы), 1032 номерлы цехлары контроль мастеры **Гаязова** Илсөяр Әхмәтхан кызына; 204 номерлы цехның чорнау машинасы машинисты **Гаязова** Равия Билал кызына; 203-10 номерлы цехның җиңсәләрне пресслаучы-кургаш коючысы **Миндубаев** Айрат Әнвәр улына; 101-11 номерлы цехы әзерлек участогының резин катнашмалар вальцовкалаучысы **Низамов** Рәис Миңгазиз улына **«Татарстан Республикасының атказанган химигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм театр сәнгатен үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен «К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Хәсәнов** Илгизәр Галимҗан улы Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәре Советы рәисе урынбасары **Кашкаров** Владимир Михайлович; Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе урынбасары **Чубаров** Александр Анатольевич; отставкадагы Татарстан Республикасы Югары Суды Рәисе урынбасары **Шәрифуллин** Риф Камил улы; Татарстан Республикасының мәдәнирухи мирасын саклауга һәм баетуга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасының мордва милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы советы әгъзасы **Новиков** Сергей Владимирович **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мамадыш төбәкне өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе фәнни хезмәткәре **Давыдова** Гөләндәм Гарафетдин кызына; Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Чирмешән авылара үзәк китапханәсе» муниципаль бюджет учреждениесенең Олылар өчен үзәк район китапханәсенең хезмәт күрсәтү бүлеге мөдире **Игнатьева** Маргарита Владимировнага; Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Үзәкләштерелгән клуб системасы» (район Мәдәният йорты) муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең клуб формированиесе җитәкчесе **Крайнова** Наилә Сәет кызына; «Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәренең балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директоры **Поверенов** Николай Юрьевичка; «Горький исемендәге мәдәният, сәнгать һәм халык иҗаты үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе хормейстеры **Попова** Кристина Рәис кызына; «Арча балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү оешмасы директоры **Сабирова** Гөлнара Барый кызына; «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директоры **Слимова** Ирина Михайловнага; «Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәренең балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең фортепиано классы буенча укытучысы **Слинкова** Октябрина Владимировнага **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Язучы фикере

Агрономия законы

Әле менә бакча тырмалап йөрим дә, күңел гел үткәннәргә кайта. Күршеләрдә беркем дә күренми, бакчада мин берүзем генә. Бәрәңге бакчасын мин генә шулай тырмалап чыгам. Бүтәннәр алай итми...

Кечкенә вакытта кызык иде, аз гына вакытың табылып, тыңлап утырырлык мөмкинлеген чыктымы – әби-бабайлар үзләренең яшь вакытын сөйләргә тотыналар. Башта рәхәтләнеп тыңлыйсың аны, чынлап та кызык булды микәнни, дип аптырыйсың да әле. Бераз гына шаттыра да торганнардыр инде. Чәчләре агарып, битләре җыерчыкланып, куллары кытыршыланып беткән әби-бабайларның кайчандыр синең шикелле бот буе гына бала булуына берничек тә ышанып булмый. Соңыннан бераз төшенәсең инде, беркемнең дә бабай булып тумаганын аңлый башлыйсың. Ә алар үзләренең яшь вакытларын сагына, күрәсең, аз гына җай чыктымы – сөйләргә тотыналар. Кайберләре кырыгышар тапкыр сөйләнелгән, ятланып беткән инде аларның. Шулай да тыңлыйсың, ташлап качып булмый. Әби-бабайлар фани дөньядан китеп, әти-әниләр картая башлый. Шуннан алар үзләренең яшь чакларын сөйләргә тотына. Бер тыңлыйсың, ике... Меңенче тапкыр да тыңлыйсың, әнтән генә үрталеп куйсаң да, ташлап качып булмый... Соңыннан сагындыра инде ул вакытлар, сагынсаң да, кире кайтара алмыйсың. Тора-бара үзебез дә өлкәнәеп, әби-бабайлар, әти-әниләр халәтенә керәбез бугай. Әле менә бакча тырмалап йөрим дә гел үземнең яшь вакытларны искә төшерәм. Ул бакчаны әллә ничәнче тапкыр тырмалыйм инде бит. Бәрәңгесе күренми дә әле, ә чүп үләннәр мыжгып тора.

Бездән бик ерак яшәми торган Зөфәр абый бар иде. Агроном. Бик уңган, бик булдыклы кеше. Колхозда гына түгел, әллә нәрсәләр үстереп, районда да танылган шәхес. Танылуы бер хәл инде аның, авылда аңа артык әһәмият бирмиләр бугай. Әмма ул бик кешелекле, ярдәмчел да иде. Үзенең абруе белән генә дә әллә кемнәрне әллә нинди бәлаләрдән аралап калган икән, дип сөйлиләр иде.

Бер мәлне бакчада тырма тартып йөрим, тыкрык буеннан Зөфәр абый үтеп бара.

– Һо, Марат, менә маладис! – дип дәртләндерде бу. – Әниең кушмыймыни?

Миңа шундый абруйлы кешенең исемем белән эндәшүе ошады. Ул кем дә мин кем бит инде. Әле тырма сабы бое булыр өчен дә ике тапкыр үсәсем бар.

– Юк, әни кушмады, – дидем, бераз кыенсынып. – Үзем...

Дөресен генә әйткәндә, бу бакча тырмалаудан бигрәк, уен шикеллерәк нәрсә иде. Тырманы тартасың да басуларны иңләп йөргән трактор шикелле дырылдап йөрисең. Борылмаларда кых-кых килеп тизлек алыштырасың, артка чигәсең, кайчагында газга ныграк басып, көрәк тавышы беләр «дрррр» дип тырманы сөйрисең. Без комлыкта да тракторлы уйный торган идек. Кызык бит инде. Ә монда чын басу шикелле, берүзеңә бер бакча. Әле мин болай эшләргә ярыйммы-ярамыймы икәнен дә белми идем.

– Дөрес эшлисең син, – дип елмайды Зөфәр абый. – Чүп үләннәр җепсел генә вакытта тырмалап чыксаң, бакча чиста була.

– Ә нигә берәү дә тырмаламый? – дип сорадым мин.

Зөфәр абый көлеп җибәрде:

– Барысы да белми аны, Марат. Бу – агрономия законы.

Ул узып киткәч, мин чынлап тырмаларга тотындым. Зөфәр абый дөрес әйткән бугай, чүп үләннәрнең җепселләре була икән, алар өскә калкып кала. О, боларның барысы да үсеп чыгасы итсә... Әни эштән кайткачы тырмалап бетердем. Әйбәтлек эшләдем дип сөенәм инде үземчә. Һәм әнтән генә кабатлыйм: «Агрономия законы...»

Ул елны чынлап та бакча чиста булды. Мин моңа нык игътибар иттем. Күршеләрнеке белән чагыштырып та карадым әле. Шуннан бүтән елларда да тырмаларга күнегеп киттем. Файдасы тия икән. Чынлап та, бакчада чүп күпкә азрак була. Агрономия законы эшли.

Менә быел да бакча тырмалап йөрим. Бик эшлисе килми, күңел үсәрлек түгел. Быел һава торышы әллә нигәрәк бит. Тиз кояш, үзе салкын. Җил тынып тора белми. Көн дә яңгыр явып китә. Бакча тырмалаганда көн коры булырга тиеш ул. Чүп булып бакчаны басып алачак җепселләр кояшта кибәргә тиеш. Шулай иткәндә генә яхшы була. Тәҗрибәм зур инде, моны әйбәт беләм.

Бакчаның яртысына җиттем генә дигәндә, тагын яңгыр ява башлады. Кичә дә шулай булган иде. Мондый вакытта тырмалауның артык файдасы юк инде, теге җепселләр кабат тамырларын җиргә сузып җибәрәчәк. Бернича көн шулай интегәм инде. Югыйсә яңгырга да, җилгә дә үпкәләп йөри торган гадәтем юк та бит. Шулай да аз гына күңел кымырҗый... Үзгәрде бугай ул дөнья. Нәрсәседер, барыбер, без яшь вакыттагы кебек түгел инде... Хәтта агрономия законнары эшләрлек тә мөмкинлек юк бит...

Марат КӘБИРОВ

ТӨЗЕЛЕШ һӘМ РЕМОНТ БРИГАДАСЫ
барлык төрдәге төзелеш эшләрен башкара
ЯЗГЫ ТАШЛАМАЛАР
Үзебезнең яки заказчының материалын кулланабыз.
Коймалар, терраса, фундамент, сайдинг, түбә эшләре, мунча, беседка, хуҗалык корылмалары, өй күтәру, бүрәнәләрне алыштыру, отмостка, борыс имитациясе эшләре.
Пенсионерларга 15-20% ташлама!
Өйләрне блок-хаус белән тышлау эшләре һ.б.
Мөрәҗәгать иткән көнне үк киләбез!
тел.: 8 968 618 37 78, 8 905 199 99 79
Реклама

Лилия ГЫЙМАЗОВА

«ЙӨРӘГЕМНЕ БЫЛБЫЛ ЧАКТЫ МИНЕМ...»

Гомере буе хакыйкать эзләгән ул. Дөньяны фәлсәфи яктан иңләгән. Башкалардан аерылып торган. Исән булса, быел күренекле татар шагыйре Зөлфәткә 75 яшь тулган булыр иде. Бүген ул шигырьләрендә генә яши, әмма дөньяда аның авазы яңгырый.

«Татар-информ»

Хәтер

Истәлек тактасында гына яшәмәсен иде ул. Ләкин анысы да кирәк. Казанның Татарстан урамындагы 7 нче йорт диварына Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Тукай һәм Җәлил премияләре иясе Зөлфәткә истәлек тактасы куелды. Шушы ук йортта яшәгән Празат Исәнбәт, Рөстәм Яхин, Вафирә Гыйззәтуллина, Хәйдәр Бигичев, Шаукәт Биктимеров янына. Зөлфәт исә монда гаиләсе белән 1981–2000 нче елларда яшәгән.

Зәвыклы килеп чыкты. Татарстан Президенты каршындагы мәдәниятне үстерү фондының башкарма директоры Нурия Һашимова шагыйрьнең портреты сурәтләнгән истәлек тактасына шулай дип бәя бирде. «Олуг шәхесләребезнең исемен мәңгеләштерү, аларны киләчәк буынга тапшыру – безнең бурычыбыз. Зөлфәт Маликова килгәндә, истәлек тактасын бик тырышып әзерләдек. Күреп торасыз: зәвыклы килеп чыкты», – диде ул тантаналы чарада.

Татарстанның мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин да җәмәгатьчелекнең һәм Хөкүмәтнең төп бурычы Зөлфәттәй күренекле шәхесләрнең исемнәрен мәңгеләштерүдән гыйбарәт булуын искәртте.

Татарстанның Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла Зөлфәтнең барыбызга да таныш шигъри юлларын яңгыратты:

«Тел ачылгач әйтә алсаң: «Әни!» – дип,
Тел ачылгач әйтә алсаң: «Әти!» – дип,
Күзләреңә яшьләр тулмыйсыз,
Туган телең әле бу булмас...

Бу юлларны барыгыз да яхшы беләдер. Зөлфәт – халкыбызның сөекле, күренекле шагыйре».

Тантанада Зөлфәтнең остазы Рәдиф Гаташ та бар иде. «Иҗат көчләренең берлеге, зур энтузиазм, укучыларның күп булуы, ул чактагы университет белеме – 90 нчы елларгы үзгәрешләрнең нигезе. Ул чордагы интеллигенция вәкилләре яңалыкка әзер иде. Һәм алар халкыбызны да үзгәртте. Ә Зөлфәт шуларның уртасында кайнады. Мине Зөлфәтнең укытучысы дип атыйлар. Билгеле, мин аңа мәктәптә дәрес бирдем. Ләкин мин үзем дә – Зөлфәтнең укучысы. Гомеремнең соңгы минутларына кадәр аннан өйрәнәчәкмен. Татар халкы һәм ул яклаган татар теле яшәгәндә Зөлфәтнең бөеклеге арта гына барачак. Рухы алдында баш иям», – дип сөйләде ул.

Зөлфәтнең дәрәҗәле исемнәрен инде санап киттек. Барысын берләштерә торган – халык шагыйре исеме җитмәде. Бу турыда шагыйрьгә истәлек тактасы ачканда Тукай премиясе лауреаты, шагыйрь Ләбиб Лерон да шулай диде. «Кызганыч, әмма халык шагыйре исеме бирелмәде, ләкин «мәшһүребез» сүзе шуны алыштыра».

Зөлфәтнең кызы Кадрия Хәлилова исә шагыйрьнең исемен мәңгеләштерү өчен тагын бер тәкъдимен җиткерде. «Чорыбызның ике зур шагыйре, ике дус – Зөлфәт белән Мөдәррис Әгъләмнең исемен мәңгеләштерү өчен Казанның ике чиктәш урамына аларның исемен бирү хыялыбыз бар», – диде ул.

Соңыннан һәркем Камал театрына – Зөлфәтнең тууына 75 ел тулуга багышланган «Чытырманда былбыл сайрый» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичәгә ашыкты.

«Уйлан, кешем, уйлан!..»

Сусау. Тамашачы залында бер генә дә буш урын күренмәүне башкача аңлатып булмый иде кебек. Озак вакыт ишетелми торганнан соң, халкына – Хәсән Туфан язып калдырганча, үз остазына кайтарылды шагыйрь. Якты дөнья белән бик иртә – 60 яшендә үк хушлашкан Зөлфәтнең иҗатына сәгать ярым дәвамында бүгенге җәмгыять призмасы аша карадык.

Кичәнең сценарий авторы – Фәрдия Сәфәргалиева, режиссеры – Лилия Әхмәтова. Зөлфәтне Камал театры артистлары – Илдус Әхмәтҗанов, Фәннүр Мөхәммәтҗанов, Ришат Әхмәдуллин, Илнур Закиров һәм Раил Шәмсуаров укыды. Шигырьләр генә түгел, шагыйрьнең тормыш сәхифәләре дә искә алынды бу кичәдә. Балачагы, яшьлеге, башкала белән танышкан еллары, дуслары, чордашлары, гыйшык һәм гомерлек мәхәббәте... Артистларга кушылып, экраннан Зөлфәт үзе дә сөйләде.

«Онытылмасмы без җырлаган җырлар, күмелмәсме без казыган чишмә?» Тамашаның башында ук яңгыраган һәм кешелекне уйланырга чакырган шушы сораулар һәм, гомумән, Зөлфәтнең тел, милләт, тарих һәм киләчәк турында сыкранып язганнары, аның илаһилеге... Дөрес, кичәнең нигезе болар булмады. Зөлфәт күбрәк мәхәббәт җырчысы, кошлар нәселеннән булган зат, үзебезнең егет буларак күрсәтелде. Шагыйрьне халыкка якынайтканрак дымы, тамашачы пәрдә ябылгач та торып китәргә һич кенә дә ашыкмады. «Җитмәде!» Теләми генә ишеккә агылган халыкның бу сүзләре кичәнең озынлыгына түгел, безнең янәдән шигырь тыңларга өйрәнүебезгә бәйле булса ярар иде дип өметләнергә генә кала... Кызганыч, «телдән төшми торган» шәхесләрдән аермалы буларак, Зөлфәтнең исеме күпкә сирәк ишетелә. Ә бит дөньяны аңларга түгел, аңлатырга тырышкан һәм шул җәһәттән үзен һәлакәткә «ташлаган» шагыйрьләр бик күп түгел.

Зөлфәт турында сүзебезне шагыйрьнең үзеннән дә тәгълрәк йомгаклаучы булмас:

Кардәшләрем! Сезнең җанда туган
Шигырьләрне әйтер сүз көчен
Ни өчендер Ходай миңа биргән –
Өлешемә тигән көмешем...

ЯХШЫ КӘЕФ САГЫНДА

«ТАТАР РАДИОСЫ» 20 ЕЛЛЫГЫН БИЛГЕЛӘП ҮТТЕ

«Татар радиосы»н үстереп кайттык бит әле. Туган көннәрен җиде мең кеше чакырып билгеләп үттеләр. Аралырында без дә булдык. Бал-майда йөзмәдек анысы. Тамашачыга җыр-моң дәрьясын, бүләкләр вагъдә иткәннәр иде, шулай булды да.

20 ел дәвамында халыкның яхшы кәефе сагында торган, татар җырын алга сөрүче радионы котларга җырчыларның да «иң-иң»нәре генә җыелган иде.

Концерт вакытында Татарстанның халык артисты Салават Фәтхетдинов: «Без ашыгып кына чыктык, ашыгып кына җырлап, кереп китәбез. Ә сез әле трамвайлар туктаганчы утырырсыз монда», – дип әйткән иде. Шулай булды да. Бәйрәм биш сәгатькә якын дәвам итте. Хәер, аннан соң да туктадымы икән әле ул? Шундый якын булган җырлы хитларны ишеткән йөрәк әле концерттан соң да шул көйләргә кушылып типкәндер.

Бәйрәм итәр алдыннан радиога кагылышлы булган-булмаганнар белән аның тарихын барлап алдык.

«Татар радиосы»ның тапшырулар продюсеры Назлыгөл Сөнгатова әйтүенчә, «Татар радиосы» иң зур милли радиостанцияләр арасында бишлеккә кергән беренче татар телле радио санала. «География– без киң. Зур төбәкләрне дә колачлыйбыз. 20 ел эчендә «Татар радиосы» күп кенә кызыклы проектларны тормышка ашырды. Әйтик, «Казан – Кырым – Казан» йөреше, 524 м биеклектә радиобыз диджее кунак белән эфирга чыкты. Россиядә моңа кадәр мондый күренеш булганмы икән?! Гомумән, башкарган эшләребезнең исемлеге зур һәм алар алга таба да дәвам итәчәк», – диде ул.

«Татар радиосы»ның алып баручыларын халык белә, таный, аларга тәртеп, танышлырын торасы да юк кебек. Ә менә Татарстанның атказанган артисты Рифат Зарипованың да диджейлар арасында чак кына эләкми калуын белгәнме икән тамашачы? Бу серне концерт алдыннан чиштеләр.

– 2006 елда Казан мәдәният һәм сәнгать институтында кастинг оештырдылар. Без Әбри Хәбриев белән катнаштык. 4–5 тапкыр эфирга да чыктык. Җырларыма кадәр башта сөйләмем таралды радиода. Әбри – оста, мин әле шомарман. Кызганыч, радионы ташлап китәргә туры килде. Дөресрәге, уку бетте дә авылга кайтып киттем. Печән вакыты, көтү чорына, – дип шаяру катыш сөйләде Рифат Зарипов. – Әмма хәзер инде радиода җырларым яңгырый, шөкер.

Татарстанның атказанган артисты Данир Сабирова да шундый ук язмыш язылассы булган икән. Тик сәхнәдәге микрофонын радиодагысына алмаштырмаган җырчы. «Кастингта катнашып йөрдем, Гөлназ Сафарова мине ошатты, әмма калганнар юк, шуңа алмадылар», – дип шаяртты Данир.

Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты Айдар Галимов, 13 ел «Татар радиосы»ннан башка ничек яшәдем икән, ди. «Аңа кадәр безнең җырлар кайда яңгырады икән? Кемнәр аша халыкка барып җиткән? Ул вакытта әле социаль челтәрләр дә юк иде бит», – дип фәлсәфәгә биреде җырчы.

«Татар радиосы»ның иң яшь диджее Илүзә Касыймова радиода әле бер генә ел эшли. «Әлеккән тыңлап үскән радио бу. Биредә эшләвемә чиксез шат мин. Команда – бер диген, ут! Әлек эшләгәннәре да, хәзергеләре дә һәрдаим элемтәдә тора, дус.

> **Кызыклы фактлар**
>
> ● «Татар радиосы» эфирында беренче чыгыш ясаучы диджей Булат Бәйрамов була. Ә эфирда яңгыраган тәүге җыр – Айдар Галимовныкы.
>
> ● «Татар радиосы»ның туган көн концертында 47 музыкаль композиция яңгырады. 15 башкаручы һәм ике гаилә дуэты чыгыш ясады.

Радиога 25, 30, 100 еллыкларны да зурлап үткәрергә насыйп булсын», – ди алып баручы кыз. Сүз уңаеннан, «Татар радиосы»ндагы Илүзә әйтеп киткән дустанә мөнәсәбәтне концерт азагында оештыручы команда сәхнәгә чыгып исбатлады: радионың гимнын күмәк башкардылар.

Салават абый «трамвай туктаганчы утырасыз» дип куркытып куйса да, халык арымады булса кирәк. Димәк, концерт энергия өсти алган. Моннан тыш, бүләкле булып та кайтып китте әле кайсылары. Алар чынлап та саллы иде («Айфон», күзләргә операция ясату өчен сертификат, мәсәлән). «Татар радиосы»ның иганәчеләре тамашачыларны чынлап та куандырырга тырышкан.

Әлбәттә, төп бүләк – җанга якын җырлар. Концертның тамашачысы Ләйсән Харисова шулай ди. «Татар радиосы»н күбрәк иртәнге-кичке сәгатьләрдә тыңлый икән. «Татар телен шомарту, мохитне югалтмау өчен, татар телле радионы кушып куярга тырышам. Авылда да тыңлыйбыз», – ди ул. Бәйрәм концертында Элвин Грей чыгышына сокланган әңгәмәдәшебез. «Энергиясе белән бөтен залны җырлата, күтәрә алды. Гомумән, күп кенә җырчылар үзләренең энергетикасы белән сокландырды бу кичне», – дип, хисләрен уртаклашты Ләйсән.

Туй үпкәсез булмагандай, концерт та шома гына бармады, билгеле. Талантлы артист кавеменен: «Нишләп мин бер генә җыр җырлыйм? Нишләп мин программада юк?» – дигән сүзләре дә ишетеләләде.

Хәер, хаталары халык гафу итәр әле. Татар моңы, җыры, яхшы кәеф хакына. Ә «Татар радиосы» – әнә шулар сагында.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7061 данә
Гомуми тираж – 16033 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 274

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Кучерен бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).
16+